**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№1** **10.12.2019**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Тымытык авыл җирлеге составына керүче,
Тымытык авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 08 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде:

«Сез 2020 елда Тымытык авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының һәм катнашучыларының, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентларның 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә, аны 2 төркем инвалидлар өчен 200 сум итеп билгеләп, бер тапкыр түләүне киметүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне хәл итүгә юнәлдерүгә юнәлдерүгә килешәсезме:

- Тымытык авылы М. Җәлил урамында юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Тымытык авылында Чапаев ур., Свердлов ур., Яшьләр ур., Кече Бакча ур., Яңалиф ур. буенча вак таш белән юлларның чокырларын ремонтлау (сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Тымытык авылында юл билгеләре сатып алу;
- Тымытык авылында урамнарны яктырту, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергияне саклый торган лампаларны урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;
- Тымытык авылы территориясендә җыештыру, көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарларны вакытлыча җыю, чистарту;
- Тымытык авылында «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Яңа ел» бәйрәм чараларын үткәрү өчен бүләк, сувенир продукциясе сатып алу;
- Тымытык авыл мәдәният йортында өлешчә косметик ремонт;
- Тымытык авылында спорт чараларын үткәрү өчен бүләк, сувенир продукциясе сатып алу;
- Тымытык авылындагы юлларны кардан чистарту;
- Тымытык авылында җәйге чорда территорияләрне чабу;
- Тымытык авылында коры агачлар, куаклар киселү;
- Тымытык авылында урам исемнәре язылган күрсәткечләр сатып алу (әзерләү) һәм урнаштыру (килешү буенча эш өчен түләү);

« РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар жыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда, сайлау хокукына ия булучы катнашучылар исемлегендә 965 кеше теркәлгән, җыенда тавыш бирүдә катнашучылар саны - 605 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
халык җыенында катнашучы 573 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде; җыенда катнашучы 32 кеше «Юк» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар чыгарды:

1. Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге составына керүче Тымытык авылында узган халык җыенын узган, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул итәргә: «Сез 2020 елда Тымытык авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының һәм катнашучыларының, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентларның 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә, аны 2 төркем инвалидлар өчен 200 сум итеп билгеләп, бер тапкыр түләүне киметүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне хәл итүгә юнәлдерүгә юнәлдерүгә килешәсезме:

- Тымытык авылы М. Җәлил урамында юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Тымытык авылында Чапаев ур., Свердлов ур., Яшьләр ур., Кече Бакча ур., Яңалиф ур. буенча вак таш белән юлларның чокырларын ремонтлау (сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Тымытык авылында юл билгеләре сатып алу;
- Тымытык авылында урамнарны яктырту, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергияне саклый торган лампаларны урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;
- Тымытык авылы территориясендә җыештыру, көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарларны вакытлыча җыю, чистарту;
- Тымытык авылында «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Яңа ел» бәйрәм чараларын үткәрү өчен бүләк, сувенир продукциясе сатып алу;
- Тымытык авыл мәдәният йортында өлешчә косметик ремонт;
- Тымытык авылында спорт чараларын үткәрү өчен бүләк, сувенир продукциясе сатып алу;
- Тымытык авылындагы юлларны кардан чистарту;

- Тымытык авылында җәйге чорда территорияләрне чабу;

- Тымытык авылында коры агачлар, куаклар киселү;

- Тымытык авылында урам исемнәре язылган күрсәткечләр сатып алу (әзерләү) һәм урнаштыру (килешү буенча эш өчен түләү).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адрес буенча

урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Тымытык авылы, Тельман урамы, 62Б нчы йорт, 75 нче йорт.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Тымытык авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Тымытык авыл җирлеге Башлыгы Э.Х. Гыйләҗева